ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
30.04.2020.

Зеленодольск
шәһәре

**КАРАР**
№ 772

Зеленодольск муниципаль районы муниципаль учреждениеләре җитәкчеләренә 2019 елның 1 гыйнварыннан 31 декабренә кадәрге чорда керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр бирү хакында

Россия Федерациясе Президентының «2019 елның 1 гыйнварыннан 31 декабренә кадәр хисап чорында керемнәр, чыгымнар, милек һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр тапшыру хакында» 2020 елның 17 апрелендәге 272 номерлы Указы, Татарстан Республикасы Президентының «2019 елның 1 гыйнварыннан 31 декабренә кадәр хисап чорында керемнәр, чыгымнар, милек һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү турында » 2020 елның 24 апрелендәге ПУ-250 номерлы Указы нигезендә, Татарстан Республикасы «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1.2013 елның 15 мартында Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 413 номерлы карары белән расланган (Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2015 елның 18 февралендәге 323 номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләр белән) Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфасына эшкә керүче зат һәм Зеленодольск муниципаль районы муниципаль учреждениесе җитәкчесе тарафыннан үз керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшыру турында Нигезләмә белән билгеләнгән, Зеленодольск муниципаль районы муниципаль учреждениеләре җитәкчеләренә үз керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, 2019 елның 1 гыйнварыннан 31 декабренә кадәрге хисап чорына кадәр белешмәләр бирү срогын 2020 елның 1 августына кадәр озайтырга.

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасары А.В.Старостинга йөкләргә.

Зеленодольск муниципаль районы
Башкарма комитет җитәкчесе — М. П. Афанасьев